ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясындагы 1 өлешенең егерме тугызынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«региональ дәүләт экология күзәтчелегендә булырга тиешле, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән III категория объектларында хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекне алып бара торган юридик затлардан һәм индивидуаль эшкуарлардан калдыклар барлыкка килү, аларны утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру турындагы хисаплылыкны кабул итүне гамәлгә ашыру;».

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 11 май
№ 25-ТРЗ